**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «13» декабреннән № 50-387

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законыны, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 91, 92 һәм 93 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (№2-9, 16.10.2015 ел; №9-32,11.02.2016 ел; №18-82, 28.09.2016 ел; №20-103, 14.12.2016 ел; №25-132, 17.04.2017 ел; №28-150 17.08.2017 ел; №31-180, 14.12.2017 ел; №37-209, 25.05.2018 ел; №43-252, 13.12.2018 ел; №50-299, 05.07.2019 ел; №61-378, 04.06.2020 ел; №10-70, 02.06.2021ел; №16-124, 09.12.2021 ел; №24-181, 7.07.2022 ел; №32-245, 16.03.2023 ел; №43-332, 27.03.2024 ел карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Уставның 6 статьясындагы 1 өлешенең 26 пунктында «муниципаль район территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Уставның 6.1 статьяныңдагы 1 өлешенең 12 пунктында «муниципаль район территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. Уставның 8 статьясының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен, Татарстан Республикасының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тиешле вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында җирле бюджетларга бирелгән субвенцияләр чикләрендә җаваплык тоталар.» (01.01.2025 елдан үз көченә керә);

1.4. Уставның 25 статьясына түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:
«3. Район Советы җирле администрацияне формалаштыруда, шул исәптән җирле администрация башлыгы урынбасарларын, җирле администрациянең тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары җитәкчеләрен билгеләп куюны раслауда яисә килештерүдә катнашырга, шулай ук мондый катнашуның формаларын һәм тәртибен билгеләргә хокуклы .»;

1.5. Уставның 39 статьясының 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә: «14) аларның чит ил агенты статусы алу.»;

1.56 Уставның 44 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Район Башлыгының вәкаләтләре түбәндәге очракта вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән эштән китү;

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74.1 статьясы нигезендә отставкага китү»;

4) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфадан читләшү;

5) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылу;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылу яисә вафат дип игълан итү;

7) судның гаепләү карарының үз көченә керүе;

8) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына күчү;

9) Россия Федерациясе гражданлыгын яки чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара килешүендә катнашучы чит ил дәүләте гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яки яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы булу;

10) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алу;

11) суд тәртибендә билгеләнгән сәламәтлек торышы буенча район башлыгы вәкаләтләрен тотрыклы рәвештә гамәлгә ашыра алмау;

12) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә, шулай ук муниципаль берәмлек бетерелгән очракта, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору;

13) җирлекнең шәһәр округы белән берләшүенә бәйле рәвештә муниципаль берәмлек статусын югалтуы;

14) район чикләрен үзгәртү яки районның шәһәр округы белән берләшүе нәтиҗәсендә килеп чыккан сайлаучыларның санын 25% тан арттыру;

7) гражданнарны турыдан-туры ихтыяр белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый актны бастырып чыгару срогын бозу;

16) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү.

17) Район Советы депутаты вәкаләтләре 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлар (кертемнәр) булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүне үтәмәү, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның

гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.

2. Россия Федерациясе Президентының ышанычын югалтуга бәйле рәвештә, район Башлыгының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

1) муниципаль район Башлыгы, аның ире яки хатыны һәм балигъ булмаган балаларының «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аңа ия булу, шәхси акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) файдалануны тыю турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән тыюны үтәмәве;

2) район Башлыгына муниципаль сайлауларда сайланган затларга карата счетлар (кертемнәр) ачу яки булу, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акча һәм кыйммәтләрне саклау, күрсәтелгән затлар район Башлыгын сайлауларда кандидатлар буларак теркәлгән чорда чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану фактын билгеләү. Шул ук вакытта «чит ил финанс инструментлары» төшенчәсе әлеге өлешнең 1 пунктында күрсәтелгән Федераль закон белән билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

3. Район башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 - 11 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча, яңа район Башлыгын сайлау вәкаләтләре туктатылганнан соң алты айдан да соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта, әгәр район Советы вәкаләтләре срогы чыкканчы алты айдан да ким вакыт калса, район Башлыгын сайлау яңа сайланган район Советының беренче утырышында гамәлгә ашырыла.

4. Район Башлыгы, аңа карата район Советы тарафыннан аны отставкага җибәрү турында карар кабул ителгәндә, әлеге карарның рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн эчендә күрсәтелгән карарга шикаять белдерү турында гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Суд гаризаны карарга һәм гариза биргән көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча карар кабул итәргә тиеш.

5. Әгәр Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) район Башлыгын вазыйфасыннан азат итү турындагы хокукый акты нигезендә яисә район Башлыгын отставкага җибәрү турындагы карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган район Башлыгы әлеге хокукый актны яисә карарны суд тәртибендә шикаять итсә, район Советы суд карары законлы көченә кергәнче үз составыннан сайлана торган район Башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хокуклы түгел.

1.7. Уставның 48 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктының җиденче абзацында «район территориясендә, район составына керүче авыл җирлекләре территорияләрендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны саклауны булдыру, гамәлгә ашыра, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.8. Уставының 79 статьясынага түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Районның җирле үзидарә органнары электр энергетикасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге электр челтәре хуҗалыгы объектларын, территориаль челтәр оешмасын яисә Татарстан Республикасы чикләрендә гамәлдә булган территориаль челтәр оешмасын системага салучы электр челтәре оешмасы объектларын түләүсез биләүгә һәм алардан файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында дәүләт теркәве узганнан соң «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы

В. М. Козлов